| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>САЛИХОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САЛИХ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2024 с.Новые Чути № 1

Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте, Хәнсвәр, Салих авылларында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге башлыгы

Карары:

1. Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 25 ноябренә 08:00 сәгатькә билгеләргә. Гражданнар җыенын уздыру урыны – «Яңа Чүте мәдәният йорты», ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Яңа Чүте авылы, Мәктәп урамы, 11.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте (көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш) җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен роторлы чапкыч сатып алу);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Чүте авылының кышкы вакытында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту).

"КАРШЫ" “РИЗА”.

3. 2024 елның 25 ноябренә 11:00 сәгатькә Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегенең Салих торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыенын уздыру урыны – Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Салих авылы, Калинин ур., 22 йорт адресы буенча урнашкан Салих авылы клубы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегендә көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен роторлы кар чистарткыч сатып алу);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Салих авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту).

"КАРШЫ" “РИЗА”

5. 2024 елның 25 ноябренә 14:00 сәгатькә Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегенең Хансвәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыенын уздыру урыны – Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Хансвәр авылы, Совет ур., 33 йорт адресы буенча урнашкан Хансвәр клубы.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Хәнсвәр авылы, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары

гаиләләреннән тыш җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:
- Ремонт, коймаларны кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Хәнсвәр авылы зиратын киртәләү өчен материаллар сатып алу);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы вакытта Хәнсвәр авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту).

"КАРШЫ" “РИЗА”

7. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга (https://www.bavly.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.
8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы И. Н. Хәйруллин